**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«17» 06 2022 ел №1774

«Тукай муниципаль районында Артамоновка авылына керү юлы» автомобиль юлын реконструкцияләү» линия объекты өчен территорияне планлаштыру проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге нигезендә, Иске Абдул авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ**

1. «Тукай муниципаль районында Артамоновка авылына керү юлы» автомобиль юлын реконструкцияләү» линия объекты өчен территорияне планлаштыру проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, техник регламентлар таләпләре нигезендә алып барырга.
3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин